Ятмас-Дусай авыл җирлеге Советы
Кукмара муниципаль районы
КАРАРЫ

2023 елның 30 июне , № 15

Кукмара муниципаль районы Ятмас Дусай авыл җирлегенең Шепшеңәр авылында гражданнар Җыенының 19.11.2022 елдагы 1 номерлы «халыктан үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча үткәрелгән халык җыены нәтиҗәләре турында»гы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча, Шепшеңәр авылында халык җыенын билгеләп кую турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында " 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Ятмас-Дусай авыл җирлеге Советы карар бирә :

1. 2023 елның 11 июленә 11 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлеге Шепшеңәр авылында гражданнар Җыенының 19.11.2022 елдагы 1 номерлы «халыктан үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча үткәрелгән халык җыены нәтиҗәләре турында»гы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча, Шепшеңәр авылында гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Шепшеңәр авылы, Мәктәп урамы, 10в йорт адресы буенча урнашкан Шепшеңәр авылы мәчет бинасында үткәрергә.
2. 2023 елның 11 июленә 16 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлеге Шепшеңәр авылында гражданнар Җыенының 19.11.2022 елдагы 1 номерлы «халыктан үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча үткәрелгән халык җыены нәтиҗәләре турында»гы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча, Шепшеңәр авылында гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Шепшеңәр авылы, Мәктәп урамы, 10в йорт адресы буенча урнашкан Шепшеңәр авылы мәчет бинасында үткәрергә.
3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: Кукмара муниципаль районы Ятмас Дусай авыл җирлегендә узган халык җыены нәтиҗәләре турында «19.11.2022 елдагы 1 номерлы» Кукмара муниципаль районы Ятмас Дусай авыл җирлегендә үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча халык җыены карарына үзгәрешләр кертү белән килешәсезме?:
   2 пунктның 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
   - Шепшеңәр авылында юлларны карап тоту, ремонтлау һәм вак таш белән каплау (килешү буенча түләү, смета һәм технадзор өчен түләү);».
   - -2 пунктны түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга: Шепшенар авылында һәйкәл төзү һәм төзекләндерү (килешү буенча түләү, смета һәм технадзор өчен түләү);".

« РИЗА» "КАРШЫ"

3. Җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга

Ятмас- Дусай
авыл җирлеге башлыгы Ф. Х. Гарифуллина